РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ**
**ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

улица К.Маркса, дом 46,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ**
**ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

К.Маркс урамы, 46 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-31-80, тел/факс 5-27-27, E-mail: chistay@tatar.ru

№ 29/1 2018 елның 23 ноябре

***Решение*** ***Карар***

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районының Чистай шәһәр
Советының 10.09.2015 елгы “Физик
затлар мөлкәтенә салым турында”гы
43/1 нче карарына үзгәрешләр
кертү турында

Россия Федерациясенең Бюджет һәм Салым кодекслары нигезендә, гаилә институтын яклау һәм ныгыту максатында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советының 10.09.2015 елгы “Физик затлар мөлкәтенә салым турында”гы 43/1 нче карарына ( Чистай шәһәр Советының 26.10.2015 елгы, 2/5нче , 24.10.2018елгы 28/2нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге 2.2 пункты белән тулыландырырга:

“2.2. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә:

2.2.1.18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарны;

2.2.2. әлеге пунктның 2.2.1. пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын,”;

1.2. түбәндәге эчтәлектәге 2.3 пункты белән тулыландырырга:

“2.3. Россия Федерациясенең Салым кодексында каралганча шулай ук салым түләүчеләрнең башка категорияләренең дә салым ташламасына хокукы бар.”

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советының 24.10 2018 елгы “Физик затлар мөлкәтенә салым турында”гы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 10.09.2015 елгы 43/1 нче карарына үзгәрешләр кертү турында”гы 28/2нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Әлеге карарның тәэсире 2017 елның 1 гыйнвареннан физик затлар мөлкәтенә салым исәпләү белән бәйле хокукмөнәсәбәтләренә җәелдерелә, әлеге карарның 1.1. пунктының дүртенче абзацыннан кала, аның тәэсире 2019 елның 1 гыйнвареннан физик затлар мөлкәтенә салым исәпләү белән бәйле хокукмөнәсәбәтләренә җәелдерелә, әмма аны рәсми бастырган көннән бер ай үткәннән соң.”.

3. Әлеге карарны “Чистопольские известия” газетасында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүматлар порталында (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталында “Интернет” мәгълүмати- телекоммуникацион челтәрендә Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatar.ru) бастырырга.

4. Әлеге карарның тәэсире 2018 елның 1 гыйнвареннан физик затлар мөлкәтенә салым исәпләү белән бәйле хокукмөнәсәбәтләренә җәелдерелә, әлеге карарның 1.2. пунктыннан кала, аның тәэсире 2017 елның 1 гыйнвареннан физик затлар мөлкәтенә салым исәпләү белән бәйле хокукмөнәсәбәтләренә җәелдерелә, әлеге карарның 2.1. пунктыннан кала, аның тәэсире әлеге пункт белән билгеләнгән сроклар нигезендә физик затлар мөлкәтенә салым исәпләү белән бәйле хокукмөнәсәбәтләренә җәелдерелә.

5. Әлеге карарның үтәлүенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А.Иванов